**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
**16 январь 2019 ел**

**КАРАР**
**№ 159**

**Советның 30.04.2018 ел № 122 «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартында 182 номерлы карары белән расланган «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары" турында карарына үзгәрешләр кертү турында” карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 30 апрелендәге 122 номерлы карарына (Советның 2018 елның 20 сентябрендәге 145 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 2.1 пунктның 3 абзацында «4,65» санын «6,72» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы http://pravo.tatarstan.ru/ хокукый мәгълүмати рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә totам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина